КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 9 сентябрь г.Казань № 744

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен раслау турында» 2022 ел, 6 июнь, 522 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 18 август, 855 нче; 2023 ел, 20 ноябрь, 1491 нче, 2024 ел, 07 май, 311 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибенә, түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 10 статьясындагы беренче өлешенең 7 пунктының унынчы абзацы нигезендә файдалануга бирелә торган гомумтаралган файдалы казылмалар булган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә җир асты байлыкларыннан файдаланучылар магистраль нефть үткәргечләрне, нефть продуктларын һәм аларның аерылгысыз технологик өлешләрен төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау эшләрен башкаручы магистраль торбаүткәргечләр буенча нефть һәм нефть продуктларын транспортлау өлкәсендә табигый монополия субъектлары булырга мөмкин.

«Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 10 статьясындагы беренче өлешенең 7 пунктының унберенче абзацы нигезендә файдалануга бирелә торган гомумтаралган файдалы казылмалар булган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә җир асты байлыкларыннан файдаланучылар магистраль газ үткәргечләрне һәм аларның аерылгысыз технологик

өлешләрен төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау эшләрен башкаручы торбаүткәргечләр буенча газ транспортлау өлкәсендә табигый монополия субъектлары булырга мөмкин.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен яки берләштерелгән лицензия буенча аларны геологик өйрәнүне, разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен, эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итүгә яки техник су белән тәэмин итүгә файдаланыла торган җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен, җир асты суларын разведкалау һәм чыгару өчен яки җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны чыгару максатларында геологик өйрәнү өчен, коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яки) коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итүгә яки техник су белән тәэмин итүгә файдаланыла торган җир асты суларын чыгару өчен, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен файдалануга бирү тәртибе» 2022 ел, 15 июнь, 564 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 18 август, 855 нче, 2022 ел, 29 сентябрь, 1050 нче, 2023 ел, 23 гыйнвар, 35 нче, 2023 ел, 20 ноябрь, 1491 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен яки берләштерелгән лицензия буенча аларны геологик өйрәнүне, разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен, эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итүгә яки техник су белән тәэмин итүгә файдаланыла торган җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен, җир асты суларын разведкалау һәм чыгару өчен яки җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны чыгару максатларында геологик өйрәнү өчен, коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яки) коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итүгә яки техник су белән тәэмин итүгә файдаланыла торган җир асты суларын чыгару өчен, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен файдалануга бирү тәртибенә, 2.1 пунктның «б» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәп, үзгәреш кертергә:

«магистраль нефть үткәргечләр, нефть продуктлары үткәргечләр һәм аларның аерылгысыз технологик өлешләрен төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау эшләрен башкару максатларында гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен гомумтаралган файдалы казылмалар булган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын аукцион үткәрмичә бирү турында;

магистраль газ үткәргечләр һәм аларның аерылгысыз технологик өлешләрен төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау эшләрен башкару максатларында гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен гомумтаралган

файдалы казылмалар булган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын аукцион үткәрмичә бирү турында.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин